Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кичү авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 3

. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге Кичү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 14 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кичү авылының Үзәк (56 йорттан 85 йортка кадәр), Яшьләр, Елга арты, Петровская урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Үзәк урамы, 67 йорт.

2. 2019 елның 14 нояберендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кичү авылының Мәктәп, Болын, Үзәк (1 йорттан 55 йортка кадәр) урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Мәктәп урамы, 34 йорт.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичү авыл җирлегенең Кичү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кичү авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә). .

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кичү авыл җирлеге башлыгы Г.П.Туманова